РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«31» октябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3539

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 8 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәреш кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасының 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 12 сентябрендәге 780 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 8 февралендәге 212 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 962 номерлы, 2020 елның 14 декабрендәге 1838 номерлы,

заказ № 1-851

2021 елның 2 мартындагы 281 номерлы, 2022 елның 25 октябрендәге 2451 номерлы, 2024 елның 27 июнендәге 2199 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтадагы 2 бүлекнең 1 пунктындагы 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Табл.№ 1

| №№ п/п | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Идарә башлыгы | 27 560,0 |
| 2 | Оператив дежурный | 21 200,0 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы А.Р. Исхаков